РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная, дом 37в,
Тел. 3-44-63

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423739, Качкын авылы, Үзәк ур.,
37в нчы йорт. Тел.3-44-63

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
23.04.2025г.

КАРАР
№8

Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 19.03.2020 ел, № 8 (28.02.2025 ел № 6 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының 19.03.2020 ел, № 8 (28.02.2025 ел № 6 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Усы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктыннан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:
"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип таныла торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".

1.2. 3.9_1 пунктын төшереп калдырырга.

1.3. 3.10_1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.10_1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.»

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе З.З.Ахмаев